| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2017 Казан ш. № 10-7/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары нигезендә, җайга салынулы оешмаларга салым салу системасына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2016-2018 елларга эчә торган суга, техник суга, су бүлүгә, җыентык суларны чистартуга, салкын суны транспортлауга һәм җыентык суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында» 2015 елның 30 ноябрендәге 10-35/кс номерлы карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29.01.2016 № 10-4/кс, 25.03.2016 № 10-6/кс, 15.12.2016 № 10-50/кс карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 кушымтаның 7 пунктына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «7 | «Мамадыш су каналы» ачык акционерлык җәмгыяте | | | | |
| 7.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)** | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 36,58 | | 30,77 |
| | | 01.07.2007 башлап 31.12.2017 кадәр | 37,78 | | 30,77 |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 37,78 | | 30,77 |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 39,34 | | 32,08 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 31,00 | | 26,08 |
| | | 01.07.2007 башлап 31.12.2017 кадәр | 32,02 | | 26,08 |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 32,02 | | 26,08 |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 33,34 | | 27,19» |

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2017 елга эчә торган суга, су бүлүгә, салкын суны транспортлауга һәм җыентык суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында» 2016 елның 09 декабрендәге 10-34/кс номерлы карарына кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктта «Казанның җылы белән тәэмин итү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде)» сүзләрен «Казанның җылы белән тәэмин итү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга.*

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов